КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 апрель

г.Казань

№ 297

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25май, 394 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның дүртенче абзацында «шулай ук тиешле җирлек, шәһәр округы территориясендә атмосфера һавасын саклау өлкәсендә Россия Федерациясе

законнары нигезендә атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларын урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектларның атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясау өлешендә, җирлекнең, шәһәр округының Генераль планы проектын килештерү өчен, шулай ук, тиешле җирлек, шәһәр округы территориясендә атмосфера һавасын саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә, атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларын, алар әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынты ясый һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару чыганаклары урнашачак әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый» сүзләрен өстәргә;

7.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Документ проектын караганда, әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә, килештерүче органнар түбәндәге критерийларга таяна:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы:

Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экологик куркынычсызлыгы стратегиясе турында» 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экологик куркынычсызлыгы стратегиясе һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2017 елның 26 июлендәге 861-б номерлы боерыгы белән расланган 2017-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр перспективада Татарстан Республикасының экологик куркынычсызлыгы стратегиясе һәм Татарстан Республикасы табигый-ресурс комплексын үстерү документы проекты нигезендә;

Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасына төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштыруга планлаштырыла торган функциональ зоналарны билгеләү һәм (яки) төбәк әһәмиятендәге линияле объектларның урнашу урынын күрсәтү өлешендә, документ проекты нигезендә;

территорияләрне куллануның аерым шартлары булган зоналар территорияләрен исәпкә алып;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына гамәлдәге лицензияләр нигезендә үзләштерелә торган файдалы казылма ятмаларының урнашуын исәпкә алып;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычына дучар булган территорияләрне исәпкә алып;

җирлекләр, шәһәр округлары территорияләрендә үткәрелгән атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларын исәпкә алып;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты:

җирле әһәмияттәге объектларны махсус саклана торган төбәк әһәмиятендәге табигать территорияләре чикләреннән читтә урнаштыру планлаштырыла;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген бозуга, массакүләм авырулар һәм корткычларны таратуга китерә, шулай ук төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигый территорияләрдә хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларының үлүен дә җәлеп итә торган чаралар булмау;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән торак пунктлар чикләренә җир кишәрлекләрен кертү нигезләре булу;

аеруча кыйммәтле продуктив авыл хуҗалыгы җирләре исемлегендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән торак пунктлар чикләренә кертелергә планлаштырылган җир кишәрлекләре булмау;

санитар-яклау зоналарына авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр керә торган җирле әһәмияттәге планлаштырылган объектларны урнаштыру нигезләре булу;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә торак пунктлар тирәсендә планлаштырылган саклагыч урман-болын поясларын һәм юл буйларында саклагыч урман үсентеләрен урнаштыруның нигезләре булу;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы:

муниципаль районнарның һәм аларның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында Татарстан Республикасы Законына муниципаль берәмлекләр чикләренең туры килү-килмәве;

торак пунктларның чикләрен кадастр исәбенә кую мөмкинлеге.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин